| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2014 Казан ш. № 5-46/тэ

***Җылылык бирүче оешмалар кулланучыларга бирә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2015 елга тарифлар билгеләү турында***

“Җылылык белән тәэмин итү турындагы” 27.07.2010 ел № 190-ФЗ федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр билгеләнү турындагы” 22.10.2010 ел № 1075 карарына, Тарифлар буенча федераль службаның “Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә көйләүле бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турындагы” 13.06.2013 ел № 760-э һәм “Җылылык бирүче оешмалар бирә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифларның Россия Федерациясе субъектлары буенча уртача соң чик максималь кимәлләрен билгеләү турындагы” 11.10.2014 ел № 227-э/3 боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Җылылык бирүче оешмалар кулланучыларга бирә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2015 елга календарь буенча бүленгән тарифларны шушы карарның кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләргә.
2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 гыйнвареннан 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Шушы карар аны рәсми игълан иткән көннән ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.12.2014 № 5-46/тэ
карарына кушымта

## Җылылык бирүче оешмалар кулланучыларга бирә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2015 елга календарь буенча бүленгән тариф

| Т. № | Муниципаль берәмлек, көйләнүче оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Алынган парның басымы | | | | Үткен һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2-2,5 кг/см$^2$ | 2,5-7,0 кг/см$^2$ | 7,0-13,0 кг/см$^2$ | > 13,0 кг/см$^2$ | |
| | Әгерҗе муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | “Тепло” ҖЧҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тарифлар тоташу схемасы буенча дифферентланмаган очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2015-30.06.2015 | 1616,42 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2015-31.12.2015 | 1836,25 | - | - | - | - | - |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 2 | “Казэнерго” ААҖ | | | | | | | |
| 2.1 | Кулланучылар өчен, тарифлар тоташу схемасы буенча дифферентланмаган очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2015-30.06.2015 | 1201,00 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2015-31.12.2015 | 1309,09 | - | - | - | - | - |
| 2.2 | Халык (тарифлар НДСны исәпләми күрсәтелгән) * | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2015-30.06.2015 | 1417,18 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2015-31.12.2015 | 1544,73 | - | - | - | - | - |
| 3 | “Казан силикат стена материаллары заводы” ҖЧҖ | | | | | | | |
| 3.1 | Кулланучылар өчен, тарифлар тоташу схемасы буенча дифферентланмаган очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2015-30.06.2015 | - | - | - | 1015,31 | - | - |
| | | 01.07.2015-31.12.2015 | - | - | - | 1300,48 | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатында бүленә

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге